**СОВЕТ**
**АКБУРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Октябрьская, д. 44,
с. Акбуре, 423197

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АКБҮРЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Октябрь урамы,44 нче йорт
Акбүре авылы, 423197

тел.: (8-84348) 3-62-40, факс: (8-84348)3-62-40, Akbur.Nsm@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**Яңа Чишмә муниципаль районы Акбүре авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

“ 24“ сентябрь 2018 нче ел № 50-89

# ЯҢА ЧИШМӘ РАЙОНЫ АКБҮРЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БИЛӘМӘЛӘРЕНДӘ ҮЗАРА САЛЫМ ҖЫЮ ҺӘМ КУЛЛАНУ БУЕНЧА РЕФЕРЕНДУМ КӨНЕН БИЛГЕЛӘРГӘ

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлауга хокукы һәм референдумда катнашуга хокукы турында”гы Федераль законның, 12 нче июнь 2002 нче ел “67-ФЗ, 15 нче матдәсе нигезендә, шулай ук “Россия Федерациясендә үзҗитәкчелекне оештыру турында” Федераль Законның, 6 нчы октябрь 2003 нче ел № 131-ФЗ, 22 нче, 56 нчы матдәсе нигезендә, “Җирле референдум турындагы” Татарстан Республикасы законы 24 нче март 2004 нче ел, № 23-ТРЗ, 17 нче, 18 нче матдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы, “Акбүре авыл җирлеге” Устанының 11 нче матдәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Акбүре авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 нче елнын 14 сентябере №21 номерлы”Референдум үткәрүгү башлангыч бирү” турындагы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Акбүре авыл җирлеге Советының 2018 нче елнын 14 сентябере №49-88 номерлы”Референдум үткәрүгү башлангыч бирү” турындагы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Акбүре авыл җирлеге Советы

**КАРАР** бирә:

1. Акбүре авыл җирлеге биләмәсендә, үзара салым җыю һәм куллану буенча, 2018 нче елның 18 нче нояберенә референдум көнен билгеләргә.
2. Референдумда каралачак сорауларны барларга:

“Сез , Акбүре авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән, 2019 нчы елга, 400 сум күләмендә үзара салым җыю белән килешәсезме?

Үзара салым түләүдән көндезге бүлектә укучы студентлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, 1 нче группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм сугыш

хәрәкәтләрендә катнашучыларның ялгыз калган тормыш иптәшләре, балачактан мөмкинлекләре чикле булганнар азат ителә.

Үзара салым түләүдән җыелган акчалар түбәндәге хезмәтләр өчен кулланылачак:

- Акбүре авылы урам юлларын төзүгә (Октябрь урамында);
- кышкы чорда авыл урамнарын кардан чистартуга;
- авыл суүткәгечләренә хезмәт күрсәтүгә, су белән тәэмин итүгә түләүгә;
- Сөлчә Баш авылы су белән тәэмин итү каланчасын, тирә-як биләмәсен төзекләндерүгә.

ӘЙЕ ЮК".

3. Карарны "Яңа Чишмә" район газетасында бастырырга.
4. Карар "Яңа Чишмә" район газетасы битләрендә басырылган көннән үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә йөклим.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципальрайоны Акбүре авыл җирлеге башлыгы Җ.М.Җәләлетдинов

СОВЕТ АКБУРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ